КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 июль г.Казань № 704

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген һәм анда урнашкан капиталь төзелеш объектларын алу турында

Татарстан Республикасының Арча муниципаль районында «Арча – Сеҗе» – Курса-Почмак» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) «Арча – Сеҗе» – Курса-Почмак» автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Сеҗе авыл җирлеге, Курса-Почмак авылы адресы буенча урнашкан, А.Ф.Хаҗиев (алга таба – алына торган мөлкәт милекчесе) милкендә булган, торак пунктлар җирләре категориясендәге 4 304 кв.метр мәйданлы, 16:09:180201:105 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 109 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген һәм аның территориясендәге 88,1 кв.метр мәйданлы, 16:09:180201:345 кадастр номерлы һәм 65,5 кв.метр мәйданлы, 16:09:180201:238 кадастр номерлы капиталь төзелеш объектларын (алга таба – алына торган мөлкәт) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районындагы Сеҗе авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган мөлкәт милекчесенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган мөлкәт өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен мөлкәтне алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган мөлкәт милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган мөлкәт өчен акча түләүне;

алына торган мөлкәткә Татарстан Республикасы милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган мөлкәт милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында «Арча – Сеҗе» – Курса-Почмак автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты территориясен планлаштыру һәм межалау проектларын раслау турында» 2019 елның 13 февралендәге 77 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә торак пунктлар җирләре категориясендәге 4 304 кв.метр мәйданлы, 16:09:180201:105 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин